КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 сентябрь г.Казань № 786

2020 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

2020 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын – аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

2020 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентларын.

2. 2020 елда Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмалары тулай торакларында студентлар яшәүгә норматив чыгымнар бер кешегә 1 елга 2 555 сум тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге каралары үз көчен югалткан дип санарга:

«2019 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 21 сентябрь, 810 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын

раслау турында» 2018 ел, 21 сентябрь, 810 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 25 май, 442 нче.

4. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 сентябрь, 786 нчы
карары белән расланды

2020 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында
югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыруга
норматив чыгымнар

| Әзерлек (белгеч-лек) юнәлеше коды | Әзерлек (белгечлек) юнәлеше исеме | Бер кешегә югары белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, 1 елга сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | әзерлек программалары буенча белем бирүнең көндезге формасы | | | әзерлек программалары буенча читтән торып белем бирү формасы | | әзерлек программалары буенча белем бирүнең кичке формасы | |
| | | специа-литет | бакалав-риат | магистра-тура | специа-литет | бакалав-риат | специа-литет | бакалав-риат |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 38.03.01 | Икътисад | | 120 276 | | | 11 689 | | |
| 15.03.04 | Технологик процессларны һәм җитештерүләрне авто-матлаштыру | | 138 818 | | | | | |
| 38.03.02 | Менеджмент | | 120 276 | | | 11 689 | | |
| 15.03.05 | Машина төзелеше җитеш-терүләрен конструкторлык-технологик яктан тәэмин итү | | 138 818 | | | | | 33 857 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21.03.01 | Нефть-газ эше | | 170 151 | | | 16 676 | | 41 690 |
| 13.03.01 | Җылылык энергетикасы һәм җылылык техникасы | | 138 818 | | | | | |
| 15.03.02 | Технологик машиналар һәм җиһаз | | 138 818 | | | | | |
| 13.03.02 | Электр энергетикасы һәм электр техникасы | | 138 818 | | | 13 543 | | |
| 21.04.01 | Нефть-газ эше | | | 181 163 | | | | |
| 15.04.04 | Технологик процессларны һәм җитештерүләрне автоматлаштыру | | | 147 439 | | | | |
| 38.04.01 | Икътисад | | | 128 478 | | | | |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 сентябрь, 786 нчы
карары белән расланды

2020 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын – аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Әзерлек (белгечлек) юнәлеше коды | Әзерлек (белгечлек) юнәлеше исеме | Бер кешегә аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, 1 елга сум | |
|---|---|---|---|
| | | фәннәр кандидатын әзерләү программалары буенча белем бирүнең көндезге формасы | фәннәр кандидатын әзерләү программалары буенча читтән торып белем бирү формасы |
| 12.06.01 | Фотоника, приборлар төзү, оптик һәм биотехник системалар һәм технологияләр | 159 468 | 15 947 |
| 21.06.01 | Файдалы казылмалар геологиясе, разведкасы һәм аларны эшкәртү | 159 468 | 15 947 |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 сентябрь, 786 нчы
карары белән расланды

2020 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче
мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын
тормышка ашыруга норматив чыгымнарга
төзәтү коэффициентлары

| Т/с | Учреждение исеме | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|---|
| 1. | «Әлмәт дәүләт нефть институты» югары белем бирүче дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе» | 0,960835 |

_______________________________________________